ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законының 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Мәгариф турында” 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманы гамәлгә куючы баланы карап торган һәм караган өчен ата-анадан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүне (алга таба – ата-ана түләве) һәм, әлеге Законда башкасы билгеләнмәгән булса, аның күләмен билгели. Гамәлгә куючы үзе билгеләгән очракларда һәм тәртиптә ата-ана түләвенең күләмен киметергә яисә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) аерым категорияләреннән аны түләттермәскә хокуклы. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмада баланы карап торган һәм караган өчен гамәлгә куючы түләсә, ата-ана түләве билгеләнми.”;

2) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең күләме, баланы карап тору һәм карау шартларына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының һәр муниципаль берәмлеге өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән максималь күләмнән артыграк була алмый.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 76-ТРЗ